ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.01.2016 ел. № 3

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставының 11,12 статьясы, Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ::

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"2015 елда Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән килешәсезме?:

- каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

- җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру;

- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;

- җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту); ;

ЮК ӘЙЕ".

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Башкарма Комитет Җитәкчесе Н.Н. Хуҗина